Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге Зүзәй авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«16» ноябрь 2024 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә», 2024 елның 16 ноябрендә түбәндәге сораулар белән узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

1. 2025 елда үзара салым акчаларын кертү һәм тоту турында.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 84 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 46 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

1. Беренче мәсьәлә буенча: 2025 елда үзара салым акчаларын кертү һәм тоту турында.
«.Беренче сорау буенча: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлегенә керүче Зүзәй авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, СВОда катнашучылардан, 90 яшен тутыручылардан тыш, 2025 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;
- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- ремонт, коймалар кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү.

ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 44кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 2 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге Зүзәй авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга:
- 2025 елда үзара салым акчаларын кертү һәм тоту турында.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Зүзәй авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: А.Н. Пинин

Сәләнгеш авыл җирлеге башлыгы А.Н. Пинин